РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422126, с.Сардек-Баш , Ул.Центральная , д.45 Тел./факс: (884364) 25-0-43 e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru,

# КАРАР

28 январь 2026 ел. №3

Гектарларда яисә баллогектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 2.1 пункты, 19.1 статьясындагы 8 – 11 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гектарларда яисә балло-гектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1475 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Сәрдекбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан 2025 елның 25 декабрендәге өземтәләргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Кадастр номеры 16:23:000000:383, мәйданы 525834 м2, һәм 16:23:110101:36 мәйданы 106365 м2, урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Сәрдекбаш авыл җирлеге, җирләр категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, рөхсәт ителгән куллану төре: авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, гектарларда күрсәтелгән, гади ялгыз вакланма рәвешендә, әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә булган җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукында өлешләр күләмен билгеләү нәтиҗәләрен расларга.

3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авылы башкарма комитетына, әлеге карар басылып чыккан көннән соң 30 көн узгач, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Нәбиев И.М.